Бүгенге санда



Фәрит Нәбиуллин якташларына бүләк ясады. 3 бит.


# Дуслык

Дружба

Нурлат шәһәре һәм Нурлат районы газетасы

1931 елның 9 июленнән бирле чыга

Чәршәмбе 21 октябрь 2015 ел

№77 (10606)


**22 октябрьгә һава торышы:** болытлы һава, урыны белән кар, җил көньяктан, 1-3 м/с; температура көндез 0°С, төнлә -1°С

ХӘБӘРЛӘРЕГЕЗНЕ КӨТӘБЕЗ

Телефоннар: 2-36-13, 2-36-20.

## ДЕПУТАТ ЯРДӘМ ИТТЕ

Бу көннәрдә Нурлат картлар һәм инвалидлар йортында идәннәргә ремонт һәм тәрәзәләрне алыштыру бара. Беренчесе ТР Хезмәт, мәшгульлек һәм социаль яклау министрлыгы средстволарына башкарылса, тәрәзәләрне алыштыруга ТР Дәүләт Советы депутаты, «Нурлатнефть" НГДУсы начальнигы Илгиз Салихов иганәчелек ярдәме күрсәткән. Нәкъ Илгиз Мисбахович булышлыгы белән 13 тәрәзә пластикка алыштырылачак икән. Бу хакта безгә картлар йорты җитәкчелеге шатланып хәбәр итте. Подрядчылар – "Нурлат төзелеш материаллары" ОООсы эшне озакка сузмаска ышандырганнар.

## ШАРТЛАР ЯХШЫРДЫ

Кичә капиталь ремонттан соң Нурлат район хастаханәсенең акушерлык бүлеге үз ишекләрен ачты. Бүлекчәне ачуга "ТНП-Зүзәйнефть" предприятиесе ярдәм күрсәткән.

Биредә ишек-тәрәзәләр, электр хуҗалыгын яңартудан тыш, әниләр һәм яңа туган сабыйлар өчен уңайлы шартлар да тудырылган: аз урынлы, ана һәм бала палаталары, махсус функциональ җиһаз, заманча душ һәм санитария бүлмәләре бар. Бүлекчә тулысынча заманча медицина җиһазы һәм җайланмалары белән җиһазландырылган. 1нче катта капиталь ремонт исә икенче этап булачак.


## Газетага язылып һәм бүләк от!




*Җомга, 23 октябрь көнне, редакциябез Бөтенроссия әбунә декадасы кысаларында Әбунәче көне үткәрә. Бу көнне газетабызның реклама бүлегендә киләсе елның беренче яртыеллыгына "Дуслык"ка язылган һәркемне оттырышсыз лотерея һәм зур булмаган бүләкләр көтә.*

**Рәхим итегез!**


**Газетаның электрон версиясен nurlat-tat.ru сайтында укыгыз**

# Паркларны буш тотмыйк



Автор фотосы

Президент ярдәмчесе шәһәр паркларын һәм скверларны карап чыкты

**Узган атна азагы районга ТР Президентының парклар һәм скверлар буенча ярдәмчесе Наталия Фишманның килүе белән истә калачак.**

Эш визитының максаты – Татарстанда Парклар һәм скверлар елына йомгак ясау, ел дәвамында бу юнәлештә республика программалары буенча башкарылган эшләрне карау. Нурлат – Наталия Фишман үзенең командасы белән булырга өлгергән 14нче район иде.

Парклар һәм скверлар елы Нурлат өчен истәлекле вакыйгаларга бай булды. Шуларның беренчесе, һичшиксез, шәһәрнең узган елда төзекләндерелә башлап, быел азагына җиткерелгән үзәк мәйдан. Район башлыгы Равил Кузюров һәм җаваплы затлар озатуында Наталия Фишман һәм аның командасы шәһәр буйлап сәяхәтләрен биредән башлады да. Музыкалы һәм төсле фонтаны, заманча ял эскәмияләре, вазоннары белән шәһәрлеләрнең күңелен яуларга өлгергән мәйдан кунакларда да матур тәэсир калдырды. Чираттагы тукталыш Сәлимҗанов урамындагы скверда булды. Быел биредә шулай ук күләмле эшләр башкарылды: ничәмә еллар буена ташландык хәлдә яткан скверга яңа сулыш өрелде. Әмма биредә төп төзелеш эшләре белән бергә җиһазлау, яшелләндерү буенча эшләрне тәгәллисе бар. Президент ярдәмчесе игътибарны шуңа юнәлтте дә.

– Парк-скверларны ясап кую гына аз, хәзер аларны шәһәрлеләрне җәлеп итәрлек итеп җиһазлау, халык күпләп йөри торган урынга әверелдерү турында уйларга кирәк, – диде Наталия Фишман.

Президент ярдәмчесе конкрет тәкъдим-теләкләрен дә җиткерде. Мәсәлән, быел шулай ук яңа сулыш алган Медведский скверына ни өчен әле шикәргә һәйкәл ясап куймаска, ди? Сквер бит шикәр заводы каршында ук урнашкан, аны җитәкләгән Владимир Медведский исемен йөртә. Шәһәрне элек-электән еракларга таныткан Нурлат шикәрен символлаштыручы үзенчәлекле билге дә булыр иде бу. Әлбәттә инде, башка беркайда да булмаган яңалык шәһәрлеләрне һәм шәһәр кунакларын да үзенә җәлеп итүгә хезмәт итәргә тиеш.

Чираттагы тукталыш "Дуслык" скверында булды. Кайчандыр карт агачлар үскән ташландык почмакта шундый заманча сквер торгызу Парклар һәм скверлар елында башкарылган эшләрнең иң саллысы булгандыр, мөгаен. Әмма биредә дә әле җиһазлау буенча эшләр дәвам иттереләчәк һәм ул төрле милләт халыкларын бергә туплаучы мәдәни-ял почмагы булачак. Наталия Фишман визиты барышында киләсе 2016 елда тормышка ашырылачак сусаклагыч зоналар республика программасына кертеләчәк потенциаль объектларны ачыклау буенча да эш алып барды. Киләсе елны Татарстан Президенты нәкъ менә Идел һәм Каманың сусаклагыч зоналары елы дип игълан итәргә тәкъдим кертте бит.

Лилия МӨБАРӘКШИНА

ТЕЛДӘН-ТЕЛГӘ

# Азрак авырый башлаганнар

**Районга кайткан гриппка каршы 5700 доза вакцинаның 5300ләбе файдаланылган инде.**

Нурлат үзәк хастаханәсе баш табибының эпидемиологик мәсьәләләр буенча урынбасары Татьяна Соренкова әйтүенчә, хәзер вакцинаның калган өлеше кайтуын көтәләр. Медицина хезмәткәрләре әйтүенчә, соңгы араларда сезонлы йогышлы авыруларга бәйле вәзгыять яхшы якка үзгәргән.

– Элегрәк февраль-марта респиратор-вируслы авыруларның артуы күзәтелә иде, соңгы елларда кимеде, - ди Татьяна Соренкова. – Беренчедән, илкүләм проект буенча ясала торган прививкаларның тәэсире сизелә, иммунлы катлам артты, яңа вирус барлыкка килмәде. Икенчедән, халыкны прививка белән колачлау проценты да арта бара. Мәсәлән, киләсе елга бу санны 30 процентка җиткерү планлаштырыла.

Балалар арасында да салкын тиеп авыручыларның саны арту күзәтелми. Педиатрия бүлеге мөдире Резедә Юнысова әйтүенчә, узган елның шул чоры белән чагыштырганда, авыручылар саны артмаган.

Ныклы сәламәтлеккә ия булу өчен нишләргә кирәк? Беренче чиратта, физкультура белән шөгыльләнергә, саф һавада йөрергә, рациональ тукланырга. Татьяна Соренкова организмны чыныктыру турында да онытмаска киңәш итә.

– Балалар бакчаларында чыныктыру процедуралары үткәрү мөһим, аларны кышын гына түгел, җәен дә онытырга ярамый. Биналарны еш җилләтү, дымлы җыештыру да профилактикада мөһим роль уйный, - ди табиб.

САН

**Районга барлыгы 15000 доза вакцина кайтырга тиеш.**

Сирень СӘМӘРХАНОВА

ИГАНӘЧЕЛЕК

# Алтын-көмеш чыккан җирдән туган-үскән җир якын



**– Татарстанга аяк басуга, күңелләрем нечкәрә, – ди озак еллар Свердловск өлкәсенең Березовск шәһәрендә яшәүче Фәрит Нәбиуллин туган ягына мөнәсәбәтен аңлатып.**

Ә күңелләре нечкәргәндә, "Березовский рудник" ОООсы генераль директоры, Россиянең атказанган старателе кулына гармун яки баянын ала икән. Узган шимбә көнне дә Фәрит Минәхмәтовичның шундый дулкынланган чагы иде. Әнә, Татарстанның атказанган артисты Вил Усманов җитәкчелегендә бер төркем артистлар аның туган авылы Кычытканлыга зур концерт бүләк итәргә килгәннәр. Сәбәбе татарга хас кунак ашы – кара-каршы принцибы: яшәгән Свердлау якларында иганәчелеге белән дан тоткан татар җанлы Фәрит Минәхмәт улы аларны ничәмә тапкыр олылап каршы алган, хөрмәт күрсәткән икән, артист халкы рәхмәтле була алмыймыни? Әле бит саллы сәбәбе дә бар: моңарчы зур проблема саналган авыл мәдәният йорты түбәсе Фәрит Нәбиуллин ярдәме белән яңартылган, шул уңайдан район башкарма комитеты әчке яктан косметик ремонт ясарга да булышкан. Кем әйтмешли, форсатның моннан да күңеллесе була аламы соң? Концерт хәбәре белән бергә Фәрит Минәхмәт улының үзен күрү теләге дә кузгаткан бугай авыл халкын: шимбә көнне яңарган мәдәният йортында алма төшәрлек тә урын юк иде. Күрше авыл тамашачыларының зирәгрәкләре үз урындыклары белән килеп булса да карадылар концертны. Һәм үкенмәделәр дә. Гаҗәеп җылы, дустанә аралашу, чын моң бәйрәме булды ул. Тамаша алдыннан Фәрит Нәбиуллинга рәхмәт чыгышларын район башлыгы Равил Кузюров башлап җибәрде.

– Шундый якташларыбыз белән чын күңелдән горурланабыз, ә декабрь аенда зур итеп якташлар очрашуы үткәрергә торабыз, – диде ул һәм иганәчегә Рәхмәт хаты һәм истәлекле бүләк тапшырды. Авыл җирлеге башлыгы Җәүдәт Нургалиевнең чыгышы да ялыктырмады бугай авылдашларын, күбесенә таныш вакыйгаларны әчене алган иде бит ул чыгыш.

Ә аннан сәхнә артистларга бирелде. Лилия Муллагалиева, Айгөл Бариева, "Болгар кызлары", Фәридә-Алсу, Рәсим Низамов, Вил Усманов үзе һәм баянчы Айнур Моратов чыгышларына кушылып җырлау, гөрләтеп алкышлау, аралашу дисеңме – зал белән сәхнә арасындагы якынлык соңгы минутка кадәр ныгый гына барды. Концертта җирле үзешчәннәребезгә дә өлеш чыкты алкышлардан, ә иң әсәрләндерерлек мизгелне исә авылдашларына Фәрит Нәбиуллин үзе һәм улы Салават бүләк иттеләр. Фәрит аганың кулына гармунын алуы булды, йөзе үк үзгәрде: татар көйләре, алар арасында бигрәк тә яратып уйнаган "Туган авылым" аның авылдашларына тел белән әйтеп бетерә алмаган сагыну, ярату хисләре булып түгелде. Улы Салават – консерватория тәмамлаган музыкант, Бөтенроссия конкурслары лауреаты белән парлап уйнарлык осталык каян килгән, дисәк, соңрак сер ачылды: "Березовский родник"та туган, шәһәрлеләрнең яраткан коллективына әверелгән баянчылар триосында алар байтактан бергәләшеп уйный икән бит! Мәртәбәле җитәкче өчен гаҗәбрәк мавыгу түгелме соң бу?

– Фәрит абый үз ягында бик дәрәҗәле һәм шактый кырыс та җитәкче. Аның вазифасында шунсыз мөмкин дә түгел,–ди Вил Усманов бераз серне ачып. – Музыка, баян аңа ял бирә, стресстан бушанырга булыша, дип беләм.

Ә Фәрит Минәхмәтович исә аны нәселдән килгән һөнәргә саный.

– Без үскәндә, авыл тулы гармунчы иде. Без – гаиләдә өченче буын гармунчылар, – диде ул улына горурлык белән карап, – әти һөнәрен мин, минекен улым дәвам итә.

Бактың исә, моң Салаватта өзелергә охшамый: аның улы Ильяс та кулына баян алган икән бит!

Фәрит Нәбиуллин – кызыклы әңгәмәдәш, озак еллар читтә яшәсә дә телне камил белә.

– Өйдә татарча сөйләшәбез, аннан өлкә татарлары да берләшеп, аралашып күңелле яшибез, – ди ул үзенең Березовскидагы татар-башкорт җәмгыяте попечительләр советы җитәкчесе булуына артык басым ясамыйча. Олы улы Салаватның дин кануннары тотуын, хаҗи булуын да сүз арасында гына белдек. Аның катнаш гаиләсендә җәмәгате дә исламны кабул иткән икән. Ә эшлеклелек сыйфатларына, әлбәттә, әтисеннән өйрәнгән. Без исә Фәрит Минәхмәт улы турында күбрәк белергә теләп, әңгәмәбезне дәвам итәбез.

**– Ә ничек Сез берниндн тәрәксез читят җирдә шундый зур җитәкче булып җитешә алдыгыз?**

– Мин бик гаярь һөнәрмәннәр белән янәшә эшләдем, алардан өйрәнми калу гөнаһ булыр иде, – диде әңгәмәдәшебез гади генә. Күрәсең, һөнәргә генә түгел, оештыру, кешеләр белән эшли белү сәләтенә дә өйрәткәндер аны тормыш мәктәбе: юкса, 1997 елда иң беренчеләрдән булып җәмәгать сайлаулары үтеп җитәкчелеккә сайлана алыр иде микән?

**– Ничек итеп авылыгызга булышу теләге килеп туды?**

– Очраклы сөйләшү барышында ачылды клуб түбәсе проблемасы. Мөмкинлегем булгач, бик теләп булыштым. Акча белән никадәр җиңелрәк хушлашасың, ул шулкадәр тизрәк килеп тә керә бит. Мин авылның ямен саклаган Кычытканлы халкына бик рәхмәтлемен. Миңа бу гамәлгә шундый игътибар биреләүен тою хәтта уңайсыз да.

Шулайдыр, әмма авыл мәнфәгатенә көн дә миллион бүләк итмиләр, ә халык игелеккә хәтерле һәм ихтирамлы була белә. Әнә бит, тамашачыларның берсе залдан чыкканда мәгълүм җырны исенә төшерде:

– Алтын-көмеш чыккан җирдән туган-үскән җир якын, диләр. Рәхмәт Фәритебезгә, туган җирен изге почмак итеп күңелендә саклавына, игелекле була белгәненә рәхмәт.

Сәкинә ХӘЙРУЛЛИНА,
автор фотосы

# Өстенлек–сәнәгать мәйданчыкларына

**Дүшәмбе көнне Республика Президенты Рөстәм Миннеханов җитәкчелегендәге Инвестиция Советының утырышы үтте. Аның эшендә видеоконференция режимында район башлыгы Равил Кузюров җитәкчелегендә нурлатлылар да катнашты.**

Рөстәм Миннеханов республикада инвесторларны җәлеп итәрлек максималь шартлар тудыру кирәк, дип ассызыклады. "Бу эш урыннары да, бюджетка яңа керемнәр дә", - диде ул. Әмма инвесторларны җәлеп итү өчен мөһим шарт – инфраструктураны үстерү.

Видеоутырышта әйтүләренчә, районнардан 152 проект кергән. Аларның күпчелеге сәнәгать, авыл хуҗалыгы, төзелеш материаллары җитештерүгә кагылышлы. Биредә шулай ук Нурлат районының 2016 елда сәнәгать парклары булдыру буенча өстенлекле территорияләр исемлегенә керүен дә билгеләп үттеләр. Инвестицион проектлар базасына Нурлаттан ике проект җибәрелгән.

– Килачәккә бездә инвестицион проект буларак сельхозхимия территориясе карала, - ди район башкарма комитеты җитәкчесенең беренче урынбасары Руслан Морадыймов. – Хәзер бу мәйданчык газ үткәрергә экспертиза үтә, ул район башлыгы һәм инвестор – Казан май-экстракцион заводы җитәкчелеге тарафыннан карала. Аларның логистикасы безнең шәһәр һәм район аша уза. Сельхозхимия мәйданчыгы элеватор өчен карала. Икенче проект – кирпеч заводы буенча, ул Әхмәт авыл җирлегенә караучы Пушкино торак пунктында урнашачак һәм 150 гектар мәйданны биләячәк. Хәзер заводның смета бәясен килештерү бара, инвесторлар – төрек коллегаларыбыз белән килешү имзалау стадиясендә. Төрнәс сәнәгать мәйданчыгына килгәндә, бизнес-план, концепцияләр эшләнү стадиясендә, документлар пакеты җыябыз. 2015 ел азагына кадәр без сәнәгать паркы буларак аккредитация үтәргә тиешбез. Республика Президенты безгә шундый бурыч куя. Нурлат районы "яшел" зонада, сәнәгать мәйданчыгын үстерү буенча эшләр дәвам итә. Бүгенге көндә ул 8 гектар били, без аларны аккредитацияләячәкбез һәм 2016 елның язында "Лизинг-грант", "50х50" һәм микро-займ программаларына чыгачакбыз. Икътисад министрлыгы һәм Нурлат муниципаль районы аша инвесторлар җәлеп итәчәкбез.

Безнең районда шундый мәйданчык булдырылуы турында Димитровград, Ульян, Самарадагы бизнес-даирә дә хәбәрдәр. Район башкарма комитеты җитәкчесенең беренче урынбасары әйтүенчә, алар киләләр, кызыксыналар икән. Димәк, якын киләчәктә сәнәгать мәйданчыклары да, эш урыннары да булыр һәм керем китерә башлар, дигән өмет бар.

Сирень СӘМӘРХАНОВА

БЕР УЧ ХӘБӘР

## ЯШҮСМЕРЛӘРГӘ ХОКУКЛАР ТУРЫНДА СӨЙЛИ

**Җирлекара үзәк китапханәнең хокукый мәгълүмат үзәге районыбыз яшүсмерләре өчен әзерләгән "Олы тормышта синең хокукларың" дигән китап-иллюстрацияле күргәзмә 16 октябрьдән эшли башлады.**

Шундый хокук дәресләре китапханәнең мәгълүмати үзәгенә даими йөрүче китап укучылар арасында зур популярлык казанган. Күргәзмәгә куелган китаплардан яшүсмерләр законнарны ни өчен үзләштерергә кирәклеге, үз карашыңны ничек якларга, барлык хәлләр турындагы мәгълүматны ничек бәяләргә, авыр ситуациядә үз-үзеңне ничек тотарга һ.б. турында мәгълүмат алалар. Биредә Россия Федерациясе Президенты каршындагы һәм регионнардагы балалар хокуклары буенча уполномоченныйларның телефоннарын да белергә була.

Маргарита ЛИТТА

